| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«САРАБИКУЛОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«САРАБИККОЛ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2024 елның 4 октябре САРАБИККОЛ № 23

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Сарабиккол авыл җирлеге” муниципальберәмлеге Советының 2021 елның 25 ноябрендәге 33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ ноииерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сарабиккол авыл җирлеге» Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге Советының 2021 елның 25 ноябрендәге 33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1 пунктта:

а) 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшкуарның банкротлык процедурасын бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә тәмамлау, аны түләү бурычын үтәүдән ул күрсәтелгән Федераль закон нигезендә азат ителгән;»;

б) 3 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

в) 5 һәм 6 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) җәзага хөкем ителгәннәргә карата штраф яки суд тарафыннан карар кабул итү рәвешендә амнистия яки ярлыкау турында актлар куллану, шуның

нигезендә бюджет керемнәре администраторы бурычны түләтү мөмкинлеген югалта

6) «Башкару эшчәнлеге турында»2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтарганда, әгәр күләме бурычлыга карата банкротлык турындагы эш кузгату өчен банкротлык (банкротлык) турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаган бурыч барлыкка килгән көннән биш елдан артык вакыт узган булса, башкару эшен тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан карар чыгарылганда;»;

г) түбәндәге эчтәлекле 6.1 пунктча өстәргә:

«6.1) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану яки банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турында гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул ителү;»;

2. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сарабиккол авылы,Киров урамы,4а йорт узидарә администраәия бинасында,Киров урамы буенча гомуми белем биру мәктәбе бинасында,3 а йорт, “Сатурн-Урал ҖЧҖ бинасында, Пионер урамы,45 нче йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

“Сарабиккол авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Г.Р.Гаделшина.